ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

07.04.2017 — с. Большие Мели — № 8

Олы Мели авыл җирлегенең 2017 елның язгы чорында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

“Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Олы Мели авыл җирлеге Уставы нигезендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының язгы чорда җимерелүләрдән саклануын тәэмин итү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2017 елның 5 апреленнән 31 маена кадәр Олы Мели авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында һәр күчәр өчен рөхсәт ителгән иң зур йөкләмәдән артып киткән транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә:

1.) Камилләштерелгән өслекле автомобиль юллары өчен:

- бер күчәрле транспорт чарасы өчен - 7,0 тонна;
- ике күчәрле транспорт чарасы өчен - 6,0 тонна;
- өч күчәрле транспорт чарасы өчен - 5,0 тонна;

2). Күчеш типтагы өслекле автомобиль юллары өчен:

- бер күчәрле транспорт чарасы өчен - 5,0 тонна;
- ике күчәрле транспорт чарасы өчен - 2,0 тонна;
- өч күчәрле транспорт чарасы өчен - 1,0 тонна;

2. Вакытлыча чикләү түбәндәгеләргә кагылмый дип билгеләргә:

- халыкара йөкләр ташу “Халыкара автомобиль ташуларны гамәлгә ашыруны дәүләт контроле турында һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында” 1998 елның 24 июлендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган халыкара йөкләр ташу;

автобуслар белән пассажирлар йөртү;

азык-төлек продуктларын, хайваннарны, дару препаратларын, орлык фондын, ашламаларны, почта һәм почта йөкләрен ташуны;

ягулык (бензин, дизель ягулыгы, судно ягулыгы, реактив двигательләр өчен

ягулык, ягу мазуты, газ ягулыгы) ташый торган йөк күтәрү чаралары 16 тоннага кадәр;

табигать афәтләрен яки башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен кирәкле йөк ташу;

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының региональ әһәмияттәге автомобиль юллары өчен дәүләт юл хәрәкәте иминлеге инспекциясе идарәсе һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өчен җирле үзидарә органнары белән килештереп, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авария-торгызу һәм ремонт эшләрен башкарганда кулланыла торган юл-төзелеш һәм юл-эксплуатацияләү техникасын һәм материалларны транспортировкалау.

3. "Транспорт чарасы күчәренә туры килә торган массаны чикләү" 3.12 юл билгеләрен урнаштыру юлы белән хәрәкәтне вакытлыча чикләүне Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган "Транспорт чаралары арбасы тибы" 8.20.1 һәм 8.20.2 өстәмә мәгълүмат билгеләре белән тәэмин итәргә;

4. Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» (Хохорин О.Е.) бүлегенә, юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенә (Багаутдинов Р.А) Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авылы җирлегендә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне тикшереп торуны тәкъдим итәргә.

5. 2017 елның 11 апрелենә кадәр җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында вакытлыча чикләүләр кертү турында мәгълүмат урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г. А. Фомина